
# КӨННӘР ТЫНЫЧ БУЛСЫН ӨЧЕН

## ТӘРТИП ҺӘМ ЗАКОН САГЫНА - 80 ЕЛ



(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Бөек Ватан сугышы чоры Октябрь районы милициясе өчен дә үзенчәлекле мөһим ел. Милиция хезмәткәрләрен хокук тәртибе сакчылары дип атыйлар. Ә ил өстендә болытлар куерганда аларның күбесе чын солдат шинельләре кияләр. Бу елларда Октябрь районыннан милиционерлар Маслов, Краснов, Фирсов кулларына корал алып Ватанны сакларга китәләр, аларның икесе яудан әйләнеп кайтмый. Милиция хезмәткәрләренә партизаннар отрядларында да хезмәт итәргә туры килә. Тылда дисциплина, тәртип фашизмны җиңүдә шулай ук зур әһәмияткә ия булалар. Шуңа да сугыш чорларында приказ буенча М.М.Салихов, Б.Я.Рыжков, А.Ф.Веренцов, М.А.Изотов һәм башкалар милициядә эшкә калдырылалар. Сугыш тәмамлангач милиция хезмәтенә Фирсов, Маликов кайталар. Туган отделына Курск өлкәсенең азат ителгән районнарында Совет власте урнаштыруда эшләргә өлгергән Изотов та әйләнеп кайта. Милиция күкрәкләрен сугышчан бүләкләр бизәгән М.М.Хуҗаханов, И.С.Никонов, Х.Ш.Садретдинов, А.А.Осипов һәм башка тәҗрибәле кешеләр белән тулылана. Бүлек фидакарь рәвештә көн - төн белән санашмыйча җинаятьчелеккә каршы көрәш алып бара. Намуслы хезмәтләре халык хөрмәтенә генә түгел, хөкүмәт бүләкләренә дә лаек була. Борис Яковлевич Рыжков «Сугышчан Кызыл Байрак», М.А.Изотов «Кызыл Йолдыз» орденнары белән бүләкләнәләр. В.И. Фирсов һәм М.М.Хуҗахановның сугышчан бүләкләренә милициядә эшләгән чорда «Кызыл Йолдыз» орденнары өстәлә.

Бүген милициягә илленче елларда килеп лаеклы ялга китәргә өлгергән милиционерлар А.И.Казаков, А.Г.Баһманов, Н.И.Тиманкин, Е.Е.Михайлов, В.К.Ермолаев, «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән Н.П.Тарасовны да зур хөрмәт белән искә аласы килә.

Бүген безнең хезмәтебездәге яхшы сыйфатлар - бу иң әүвәл данлы традицияләрнең дәвамы, аларның буыннан - буынга күчүе нәтиҗәсе. Бүгенге катлаулы шартларда милициягә йөкләнгән бурычларны уңышлы үтәү инанганлык, оешканлык, ныклы дисциплина, югары профессиональ һәм әхлакый сыйфатлар нәтиҗәсендә генә мөмкин.

Октябрь район эчке эшләр бүлегенең шәхси составы 1996 нчы елда әйбәт кенә нәтиҗәләргә ирешә алды. 1997 нче елның 9 аенда җинаятьләрне ачу 86,7 процент тәшкил итте. Үтерү, авыр тән җәрәхәте ясау, талау нияте белән һөҗүм итү, талау һәм көчләүләр һәммәсе ачыкланды. Күрелгән профилактик чаралар нәтиҗәсендә гомуми җинаятьчелек 1,9 процентка, алдан ниятләп үтерү 12,5 процентка, талаулар 20, җинаять җәзасына тартыла торган хулиганлык 18,6, 213 нче статья буенча хулиганлык 2,3, бурлык юлы белән милек урлау 4,3, базалардан, складлардан урлау 27,3, автомототранспортны куу 44,4, балигъ булмаган балалар тарафыннан эшләнгән җинаятьләр 50, ут төртүләр 40, җәмәгать урыннарында ясалган җинаятьчелек 58,3, урамда башкарылган җинаятьләр 81,3 процентка кимеде.

Эчке эшләр бүлегенең күп хезмәткәрләре үзләренә куелган бурычларны югары профессиональ дәрәҗәдә башкаралар. Бүген мин иң яхшылар рәтендә уголовный розыск хезмәткәрләрен, шулай ук ОЭПның өлкән оперуполномоченныйлары Кузьмин, Янилькин, өлкән тикшерүче Миронов, Фәхретдинов, тикшерүчеләр Сөләйманова, Купцова, Чугуновны атый алам. Җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалауда халык белән тыгыз элемтәдә торып эшләүче участок инспекторлары Чуркин, Семенов, Гобәйдуллин, Шәфыйков, Сөләйманов, Тәмаев та мактауга лаеклар. Балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекне кисәтү буенча зур эш башкаручы бүлек начальнигы Корбанов, инспекторлар Зәйниев, Еменькина да хөрмәткә ия хезмәткәрләр.

Һава торышы нинди булуга карамастан ДАИ хезмәткәрләре һәрчак юлда. Юл - транспорт һәлакәтләрен булдырмау өчен ДАИ бүлеге начальнигы Х.В.Әюпов, Дәүләт автоинспекторлары З.Ф.Хөснуллин, Р.Г.Әюпов, ДПС инспекторлары Н.Гайнетдинов, А.Тухтаманов, А.Сатдаров, Ф.Низаметдинов киң профилактик эшләр алып баралар. Милиционерлар Җаббаров, Вәлиуллин, Ерепов, Григорьев, шоферлар Хөсәенов, Еремеев, Нигъмәтуллин да үз эшләренә җаваплы карыйлар.

Безнең белән бергә милициянең авыр көндәлек хезмәтен безнең хатыннарыбыз һәм әниләребез дә бүлешәләр. Аларның безнең хезмәтебезнең катлаулылыгын аңлавы, җылы шәфкатьле сүзләре белән күңелләребезне күтәрә белүләре иң авыр минутларда да безгә ярдәмгә килә.

Бүгенге бәйрәм көнендә без барлык милиция хезмәткәрләрен, данлы ветераннарыбызны, гаилә членнарын милициянең 80 еллык юбилее белән котлыйбыз. Бүлек хезмәткәрләре җәмәгать тәртибен ныгытуда район хезмәт ияләре һәм халкы мәнфәгатьләрен саклауда тугрылыклы солдатлар булырлар дигән ышанычта калабыз.

**В.ИВАНОВ,**
**Октябрь район эчке эшләр бүлеге начальнигы, милиция полковнигы.**

### Саннар һәм фактлар

**Октябрь район эчке эшләр бүлегенең штатында 118 хезмәткәр исәпләнә. Аларның 71е - офицерлар, 47се - рядовой һәм сержантлар составы. Кадрлар алышыну 1,7 процент тәшкил итә.**

**Милли состав:**
**татарлар - 60 проц.**
**чувашлар - 28,8 проц.**
**руслар - 11,1 проц.**

***

**Эчке эшләр бүлегендә 15 автомашина, 12 мотоцикл, 2 компьютер, 10 автомобиль һәм 20 күчмә радиостанция, шуңа өстәп башка махсус техника: видеокамера, компьютерлар, фотоаппаратлар, магнитофоннар һ.б. бар.**

***

**Октябрь районы ДАИсында 5000 берәмлек автомототранспорт исәптә тора. Районда юллар озынлыгы 400 км. тәшкил итә. 9 айда 31 юл - транспорт фаҗигасе булып, анда 8 кеше үлде, 29ы тән җәрәхәте алды.**

# Хәвефле зонада кара - каршы

***Берәүләр үз язмышларыннан өстенрәк чыгарга, аның борынына чиртергә, ул гына да түгел, үзләренең, хәтта башкаларның да язмышларын төзәтеп булмастай иттереп җимерергә тырышалар, икенчеләр исә үзләрен куркыныч астына куеп, күп рәхәтлекләрдән мәхрүм итеп булса да әнә шул беренчеләрне тотып зарарсызландыру хакына хезмәт бурычларын башкаралар. Беренчеләре, үзләренә тулы ирек бирелгән дип уйлап, чик - чамасыз кылынсалар, икенчеләре тегеләргә каршы көрәштә законның һәр киртегенә кадәр үтәргә тырышалар. Шушы ике көч бер - берсеннән шулкадәр ерак торган бу хәвефле зонадагы шушы кара - каршы «уен»ның гаять кырыс шартлары әхлак һәм мораль, хаклык һәм гаделлек, изгелек һәм явызлык турындагы гомерлек төшенчәләрнең чын асылын ачып бирә.***

***Район эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары, криминаль милиция начальнигы подполковник Валерий Леонидович Гаврилов белән аларның һөнәри бәйрәмнәре алдыннан әңгәмәбез хокук саклау органнары службасы чылбырындагы үзәк буын булган җинаятьләрне эзләү (уголовный розыск) бүлегенең көндәлек эшчәнлеге турында барды.***



**- Валерий Леонидович, соңгы вакытта республика массакүләм мәгълүмат чараларында криминаль хәлнең уңайга үзгәрә баруы турындагы хәбәрләр еш языла. Моның шулай икәнлегенә шик белдермәсәк тә, конкрет алганда нәрсәне күздә тотып шундый нәтиҗә ясалуын беләсе килә: җинаятьләр азайдымы, әллә аларны ачу эше яхшырдымы, я булмаса башка сәбәпләр бармы?**

- Сез телгә алган факторлар гомумән республикада һәм аерым алганда безнең районда оператив хәл тотрыклылануның гади күзгә күренеп торган билгеләре. Иң мөһиме шул, туксанынчы еллар башында җинаятьчелек гомер күрелмәгәнчә арткан криминоген хәлне хәзер йомшарды һәм хокук саклау органнары аны контрольдә тоталар дип исәпләргә була. Заманында бандитлыкка каршы көрәштә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Президентларының махсус Әмерләре белән кертелгән гадәттән тыш чараларның кирәге калмады.

**- Ә бу сезнең эшегезнең күрсәткечләрендә ничек чагыла?**

- Агымдагы елның тугыз аенда барлыгы 314 җинаять эшләнде һәм бу узган елның шул чорындагыдан 6 га кимрәк. Җинаятьләрне ачу күрсәткече дә яхшырды - 86,1 урынына 86,7 процент булды. Тик бу вакыт эчендә шәхескә каршы эшләнә торган үтерү, көчләү, талау һ.б. кебек авыр җинаятьләр саны чамасыз артты. Мисал өчен, быел эшләнгән һәм барысы да ачылган 12 авыр җинаятьнең 6сы - гадәттә эчүчелек аркасында килеп чыга торган көнкүреш үтерүләре.

**- Валерий Леонидович, узган ел аеруча рәхимсезлек белән эшләнгән дүрт җинаять: подстанциядә, Яңа Иглайда, Кормыш микрорайонында һәм Бажановлар гаиләсен үтерүләр бар кешене тетрәтте. Алар хакында Сез хәзер нәрсә әйтә аласыз?**

- Иң әһәмиятлесе шул - вәхшиләрчә бу үтерүләрнең дүртесе дә ачылды, ул җинаятьләр буенча бик җентекле һәм күп хезмәт куярга туры килгән тикшерү эшләре үткәрелеп, дүрт җинаять эше дә судка тапшырылды. Республика хокук саклау органнары хезмәткәрләренең билгеле бер ярдәме тисә дә, барлык бу җинаятьләрнең безнең хезмәткәрләр тарафыннан һәм безнең версияләр буенча ачылуын да әйтәсем килә. Республиканыкылар оператив - тикшерү чаралары үткәрүнең камилрәк алымнарына ияләр. Ә без исә аларда булган техник база турында хыяллана гына алабыз. Әйтик, дүрт үтерү дә, инде хәбәр ителгәнчә, эчкерле ният белән һәм талау өчен берничә тапкыр хөкемгә тартылганнар тарафыннан эшләнгән. Бу җинаятьләрне ачу, кагыйдә буларак, аларның җинаять эшләр алдыннан төрле җирләрдән җыелып, соңыннан тиз генә таралган җинаятьчеләр төркеме тарафыннан ясалуы белән катлауланды. Шуңа да егетләребезгә тәүлек дәвамында Самарада да, Яр Чаллыда, Казанда һәм башка җирләрдә дә булып оператив - тикшерү чаралары уздырырга туры килде.

**(Ахыры 3 нче биттә).**

# СЕЗНЕҢ ТЫРЫШЛЫК КИРӘК

15 октябрьдән
15 ноябрьгәчә
«Трактор»
операциясе

## Юллар имин булсын

Агымдагы елда район тракторчылары тарафыннан 4 юл - транспорт һәлакәте ясалды.

4 нче августта «Сельхозтехника»дан Н.Шаймуков төзексез трактор белән идарә итә. Урап үтү юлыннан үткәндә тракторның тагылмасы ычкынып җәяүлене бәрдерә. Җәяүле вафат була.

26 нчы августта кичке сәгать 9да Фома авылында С.Ананасов МТЗ - 80 тракторында артка биргәндә А.Казаков өстенә барып керә. Тегесе алган җәрәхәтләренә түзә алмыйча шунда ук үлә.

Хәрәкәтне күзәтүләрдән күренгәнчә тракторларда барлыгы 2000 юл йөрү хәрәкәтләрен бозучы ачыклана. Шуларның 200е исерек хәлдә була.

Күп кенә хуҗалыкларда гамәлдән чыккан, закон буенча эксплуатацияләнмәскә тиешле тракторлардан файдаланалар. Шәхси милекчеләрнең дә байтагы бракка чыгарылган тракторларны сатып алалар. ГАИ хезмәткәрләре шундый тракторларны штраф стоянкасына ябып куялар.

ТРның авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министры приказы нигезендә К - 700 һәм Т - 150 каты каркаслар белән җиһазландырылырга тиеш. Шул таләпне үтәмәгән очракта ТР Законының 14нче маддәсе нигезендә (1993 елның 17 нче мае) хуҗалык җитәкчеләре җаваплылыкка тартылалар.

Тракторчылар арасында юл кагыйдәләрен бозуны булдырмау максатында республикада 15 нче октябрьдән 15 нче ноябрьгәчә «Трактор» операциясе үткәрелә.

Шуның нигезендә Октябрь районы ДАИсы Дәүләт техника күзәтчелеге белән берлектә юлларда һәм район хуҗалыкларында тикшерүләр үткәреләчәк.

**Х.ӘЮПОВ,**
**ДАИ бүлеге начальнигы.**



Бүлек хезмәткәрләре штабны еш кына бүлекнең «мие» дип атыйлар һәм ул күбесенчә дөреслеккә туры килә дә. Чөнки штабның төп функциясе тирәнтен анализ нигезендә идарәчелек карарларын чыгара. Шуңа күрә дә җинаятьчелек турында, җинаять эшләү ысуллары, эчке эшләр бүлеге чаралары һәм көчләре турында бөтен хәбәрләр бирегә килеп ирешә. Аннан тыш һәртөрле дежурлык графиклары, төрле «ЧП»лар булганда шәхси составның эш планын төзү дә алар җилкәсенә төшә. Штабның эшен милиция подполковнигы Н.М.Романов җитәкли, ә югары квалификацияле хезмәткәрләр һәм заманча компьютерлар - аның ярдәмчеләре.

**Рәсемдә: Октябрь районы эчке эшләр бүлеге штабы начальнигы Н.М.Романов һәм секретарь - машинистка В.П.Сторостина.**

**С.ХӘЙРУЛЛИНА**

*Сез бүген тәртип сагының*
*Тынгысыз солдатлары*
*Күмә алмый данызгызны*
*Тарихның җиле - кары.*

*Ә язмыш сезнең халыкны*
*Сынаган төрле яклап.*
*Тынычта да азмы бездә*
*Туплар атылган чаклар.*

*Сыенган сезнең җилкәгә*
*Яклау эзләгән халык.*
*Данлы сәхифәгез кайчак*
*Язылган канга манып.*

*Ә сез - һаман шул хезмәттә -*
*Талмас та икән йөрәк!*
*Көннәр имин булсын өчен*
*Нәкъ шундый йөрәк кирәк.*

## Хәвефле зонада кара - каршы

**(Ахыры. Башы 2 нче биттә).**

Көнгә 14 - 16 шар сәгать эшләделәр. Җинаять ачылганчыга кадәр бездә, эчке эшләр органнары хезмәткәрләре өстендә икеләтә - һөнәри дә, мораль дә җаваплылык ята бит.

**- Валерий Леонидович, безнең Норлатта башка зур һәм уртакул шәһәрләрнең «мактанычы» саналган оешкан җинаятьчелек бармы?**

- Әлегә бездә оешкан җинаятьчелекнең, инде әйткәнемчә, узган елгы ике шау - шулы үтерештә чагылган аерым элементлары гына чамалана. Гомумән алганда, оешкан җинаятьчелек һич тә буш урында гына барлыкка килми. Җинаятьчеләрнең бер - берсе белән элемтәсе, булачак «операцияләрнең» планнары, аларны башкару алымнары инде тегендә, «зонада» ук өйрәнелә, алар шунда ук физик һәм рухи чыныгу да узалар. Ул даирәнең идеологиясе - аларга ни кылансалар да ярый дип уйлау, принциплары - үзләрен тотылмаслар дип санауга нигезләнгән рәхимсезлек һәм тупаслык.

**- Җәмгыять җәза бирү органнарының җинаятьчеләргә каршы көрәш чаралары аз түгеллегенә инана бара. Ерып чыга алмастай тоелган ул пычракны кичү өчен сезнең хезмәткәрләр рухи көчне каян алалар соң?**

- Беренче чиратта алардагы җаваплылык хисе. Егетләребез ул эшне алардан башка беркем дә эшләмәячәген аңлыйлар. Мундир намусы дигән нәрсә алар өчен һич тә буш сүзләр түгел. Һәм әгәр дә Сез,җинаятьчелеккә каршы көрәштә уңышка ирешүдә кайсы факторның роле хәлиткечрәк дип сорасагыз, мин: хезмәткәрләрнең һөнәрмәнлеге дияр идем. Бездә, уголовный розыскда тәҗрибә биш еллап эшләгәннән соң килә дип санала, әмма хезмәткәрләребезнең күпчелегенең аның кадәр стажы юк әле. Без үзебез резонанслы үтерүләр дип саный торган теге җинаятьләрне ачылган бер ел вакыт алар өчен ике елга торырлык булды. Бездә сынау бик тә кырыс шул. Һәм егетләребез аны лаеклы ерып чыктылар. Оператив - тикшерү чараларын уңышлы төстә гамәлгә ашыруга уголовный розыск начальнигы Евгений Сидневның, бүлек хезмәткәрләре Игорь Чернов, Рәшит Гайфетдинов, Николай Куприяновның керткән өлешен рәхмәт белән билгеләп үтәсем килә. Аларның гаиләләренә, яраткан ирләренең әледән әле тәүлекнең теләсә нинди вакытында өйдән чыгып китәргә мәҗбүр булуларын аңлый һәм гафу итә алучы хатыннарына да зур рәхмәтле без. Якын кешеләре өчен һәрдаим борчылып торырга мәҗбүр булуларына да карамастан чыдамлык күрсәтүче хатыннарының ярдәме егетләребезгә шулай ук көч бирә дип саныйбыз.

**- Уголовный розыск соңгы вакытта ниләр белән мәшгуль?**

- Авыл хуҗалыгы кооперативларындагы урлауларны ачу белән. Хафизов исемендәге КХА фермасыннан 45 баш дуңгыз , 5 ат, Киекледә складтан 39 данә авторезина урлаганнар. Гаражга куелмаган машиналарны басу очраклары да ешайды. Беләсезме, җитәкчеләр һәм хуҗаларның пошмаслыгы гаҗәпләндерә. Хуҗалык объектларында, кагыйдә буларак, сак юк, ә шул ук вакытта җитәкчеләр тынычлап йоклыйлар. Моннан ары мондый хәл булырга тиеш түгел һәм без бу уңайдан район хакимиятенә представление әзерлибез һәм чара күрелер дип уйлыйбыз.

Күптән өлгереп җиткән икенче бер проблема да бар. Ул - участок инспекторларына автомобиль бирү мәсьәләсе. Уйлап кына карагыз әле, бер участок инспекторы карамагында берничә авыл бар, ә ул аларга өстән - өстән генә күз йөртеп чыгу өчен дә юлда транспорт көтеп торырга мәҗбүр. Әле бу көндез. Ә төнлә ни эшләргә кала? Шуңа күрә вакыйга булган урынга участковый иң ахыргы булып килеп өлгерә дә инде. Акыл белән уйлап караганда, участок инспекторларын инде күптән, һич югы берничә хуҗалык бергә җыелып булса да транспорт белән тәэмин итәргә вакыт. Шул хуҗалыкларның үз мәнфәгатьләре хакына булачак бит ул.

Моннан җинаятьләрне кисәтү һәм аларны ачу бердән хуҗалык өлкәсендә ныклы контроль булдыруга, икенчедән милиция хезмәткәрләрен техник яктан җитәрлек коралландыруга да нык бәйле дип нәтиҗә ясыйсы килә.

**- Ә район эчке эшләр бүлеге үзе нинди «ашыгыч эш итү» чаралары күрә?**

- Оператив тикшерү төркемнәрнең тәүлек буе дежурлыгын кертү зарурлыгы туды. Хәзер дежур часть берәр вакыйга турында хәбәр кабул итү белән 5 - 6 минуттан соң ук урынга бүлек хезмәткәрләре төркеме чыгып китә. Ә бу дәлилләүче беренчел мәгълүматны оператив төстә туплау өчен җинаятьләрне «кызуында» тикшерә башларга мөмкинлек бирә.

**- Һәм соңгысы. Сезнең хезмәткәрләр үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен ничек билгеләп үтәчәкләр?**

- Андый мондый хәлләр килеп чыкмаса, гадәттәгечә: тантаналы җыелыш, бүләкләүләр, концерт. Дуслар белән бергәләп утырмыйча да калмабыз дип уйлыйбыз - күп хезмәткәрләребезнең гаиләләре үзара йөрешәләр. Беренче тостны, билгеле инде, безнең хәвефле дә, кыен да хезмәтебез хөрмәтенә күтәрәчәкбез - һич тә йомшаклар эше түгел бит безнең эш. Бәйрәм белән сезне, кадерле коллегалар! Үзегезгә тазалык, гаиләләрегезгә шуңа өстәп сабырлык та һәм безнең кешеләргә шул кадәр дә кирәкле хезмәтебездә уңышлар телим.

**Д.ТЯМАЕВА**
**сөйләште.**

80 ел элек (1917)
Бөек Октябрь
революциясе
булды

## ВЕТЕРАН КОТЛЫЙ

Тарих аяусыз, дөнья - үзгәрүчән. Әле берничә еллар элек кенә 7 ноябрь Бөек Октябрь Социалистик революциясенең фәлән еллыгы дип иң зур бәйрәмебез итеп билгеләп уза торган идек. Кыйблалар үзгәрде, бәйрәмнәрнең яңалары барлыкка килде, искеләре җуелды, яки яңа төсмер алды.

Әмма гомере буе коммунистлар партиясен бердәнбер гадел берлек дип табынган буынга тиз генә үзгәрүе җиңел түгел. Шушы көннәрдә генә Яңа Әлмәттән хәбәрчебез Җәүдәт ага Хәйруллин шалтыратты:

- Сугыш инвалиды, мөхтәрәм хезмәт ветераны карт коммунист Хөҗҗәт Гарифулла улы Нигъмәтуллинның үтенечен җиткерергә ашыгам,- дип башлады ул сүзен. 73 яшьлек Хөҗҗәт ага шул хуҗалыкта озак еллар зоотехник булып эшләп, сугыш кырларын үткән кеше икән. Тормышының күп өлешен - 40 елын коммунист буларак җаны - тәне белән партиягә бирелеп үткәргән. Үзен партия члены итеп тою иң әүвәл аңа гадел һәм тулы канлы тормыш белән яшәргә, илнең чын патриоты булырга булышкан. Авылдашлары шаһит: агайның үз үткәненнән оялып түгел, күкрәк киереп горурланып яшәрлек хакы бар. Андый язмышлы кешенең үз идеалларына тугъры калуын гаепләп буламы?

- Хөҗҗәт ага барлык партия әгъзаларын революцион бәйрәм белән котларга тели,- дип, хәбәрчебез агайның үтенечен җиткергәч, без иң әүвәл шулай фикер йөрттек.

Ахыр чиктә, без тарихны сызып ташлый алмыйбыз ләбаса! Һәм гомерен якты киләчәк хакына идеалларга багышлап үткәргән буынның бу көнне бәйрәм итеп санавы да, безнеңчә, һич гайре табигый нәрсә түгел...

# КОТЛЫЙБЫЗ!



*Кадерле әти - әниебез* ***Габдрәшит Бәдретдин улы һәм Затия Мингалим кызы Сәйфелмөлековларның*** *бергә тормыш коруларына 50 ел тула.*

*Сезне чын күңелдән олы юбилеегыз белән котлыйбыз, сезгә киләчәктә дә тату тигез тормыш, балаларыгызның хөрмәтен тоеп озак еллар исәнлектә яшәвегезне телибез.*

*Тигез гомер насыйп булсын сезгә,*
*Гел атлагыз бергә, янәшә.*
*Сау - сәламәт, игелектә булып*
*Яшәсәгез иде йөзгәчә.*

***Барлык балалары исеменнән улы Рифкать, килене Рәисә, оныклары.***

Югары Норлат авылында яшәүче кадерле улым, тормыш иптәшем, яраткан әтиебез һәм дәү әтиебез **Камил Минвәли улы Мусинга** 7 ноябрьдә 50 яшь тулды. Кадерле әтиебез! Сине юбилееӊ белән котлыйбыз. Бәхет, шатлык, озын гомер телибез.

Әти бит ул - өйнең яме,
Ә тормышта олы бер терәк.
Сәламәт бул, әти, озак яшә,
Син бит, әти, безгә бик кирәк.
«Олыгайдым инде, кирәк бетте», - димә
Кирәк, әти, кирәк син безгә,
Авырлыклар килсә, киңәш сорап,
Киләбез без изге нигезгә.

**Иң изге теләкләр белән: әниең, иптәшең Рәйсә, кызың Гөлназ, улларың Айдар, Марсель, киявең Илгиз, киленең Гүзәл һәм оныгың Алсу.**

Фома авылында яшәүче кадерле әтиебез **Фатыйх Кәрим улы Канәфинга** 70 яшь. Әтиебезгә бәхетле озын гомер, исәнлек һәм тигез матур тормыш телибез.

Яшә, әти, тагын йөзгә хәтле,
Шат күңелләр белән гомер ит.
Җиргә кояш ничек кирәк булса
Син дә безгә шулай кирәк бит.

**Әниебез, кызлары, уллары, кияүләре, киленнәре һәм оныклары.**

*Некрасовка поселогында яшәүче кадерле апабыз* ***Сания Сәлимгәрәй кызы Төхфәтуллинаның*** *9 ноябрьдә туган көне. Без апабызга исәнлек, җан тынычлыгы теләп калабыз.*

*Ачык йөзе, тәмле теле белән безне шатландырып, балаларының игелеген күреп тагын күп еллар яшәвен телибез. Авыр тормыш юлымда әни булуың өчен, зур ярдәмең өчен, эчкерсез киңәшләрең өчен барысы - барысы өчен дә аллаһының рәхмәте иңсен сиңа кадерле апабыз.*

***Барлык балаларым исеменнән сеңелең Диләфрүз.***

# «Татлы тормышның» әче җимешләре

«Наркотикларның легаль булмаган әйләнеше һәм аларны куллану проблемасы Россиядә шундый урынга чыкты ки, аңа игътибар итмәү өендә чыккан янгынны күрмәүгә тиң».
(«Аргументы и факты» газетасының 1997 ел, 40 нчы саныннан).

Кызганычка каршы, без дә сезнең белән шул йортта яшибез, соңгы елларда наркомания бездә дә үсеш алды. Кайсы яктан куркынычлы соң ул?

Эш шунда ки, наркотик тәэсирен бер яки ике генә тапкыр татып караган сау - сәламәт кеше аның өметсез колына әйләнә һәм медицина ярдәменнән башка аннан котыла алмый. Наркотикның явызлыгы шунда да.

Әлбәттә, наркоман булып тумыйлар, яшәү рәвешендә әвереләләр. Вакытында тукталмаган, аның зыянын аңламаган кешеләр наркоманга әвереләләр.

Еш кына наркотикны җиңел уйлаучылар, кызыксынучылар һәм ошарга тырышучылар татып карыйлар, ә кайвакыт «тәҗрибәле» иптәшләре моңа этәрә.

Наркомания - ул бертуктаусыз үсә баручы чир, иң соңгы стадиясендә аның иң куркыныч яклары ачыла: тулы апатия, абынучан, тотрыксыз адымнар - менә наркомания «җимешләре».

Авыруларның тышкы халәте түбәндәгечә: ябыгудан, тиренең корылыгыннан, тешләрнең тирәнгә киткән кариесыннан, чәчләр һәм тырнаклар сынуыннан урта яшьтәге яки яшь кешеләр дә картларга охшап калалар.

Психика кинәт үзгәрә. Хроник рәвештә эч китүләр нык ябыктыра. Наркоманның йөзе шактый ямьсезләнә: соры төс ала, шешенә, чәчләре һәм тешләре коела, организмның сусызлануыннан йөзендә сырларның тулы «географиясе» барлыкка килә...

Аларның хәтере начарая, укыганнарын шунда ук оныта баралар, иң гади математик мәсьәләләрне дә чишә алмыйлар. Бөтен яңалыкны авыр үзләштерә, укуга карата кызыксынуы бик тиз сүнә. Чирле кеше тынычсыз була, аңарда ачулы - моңсу кәеф өстенлек ала. Томау төшү, төчкерү, күздән яшь чыгу, өшү һәм эсселек халәтләренең аралашып килүен кичерә. Мускуллар авырта, аяк мускулларын көзән җыера.

Наркотиклар кабул итүгә нинди сәбәпләр этәрә соң? Алар әлләни күп тә түгел: социаль яктан якланмау, иртәгеге көнгә ышанмау, түбән дәрәҗәдәге культура һәм кагыйдә булмау, җитмәүчелеккә бәйләнешле тәрбия. Боларның күбесеннән бүгенге көндә тиз генә котылу юлы әле дә юк. Шуңа да наркомания тозагына эләккән кешегә тиз арада белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аңа бары тик ул гына ярдәм итә ала.

Шунысын белергә кирәк, наркотикның турыдан - туры үзәк нерв системасына тәэсир итүе аркасында ул үз функциясен югалта. Нәтиҗәдә бу патология процессына организмның барлык органнары да кушыла һәм ахыр чиктә организмны тулысынча җимереп үлемгә китерә.

Бирегә иң мөһиме шул: чирле кеше ярдәм сорап никадәр тизрәк мөрәҗәгать итсә, шулкадәр терелүгә өмете зуррак.

Исегездә тотыгыз! Наркотиклар - тулы канлы, сәламәт, көчле, матур һәм эшлекле кеше үсеше өчен үтеп чыга алмаслык киртә сыман. Аларны куллана күрмәгез. Сәламәтлегегез, шатлыгыгыз үзегезнең кулда.

**А.АНОСОВ,**
**район үзәк шифаханәсенең фельдшер - наркологы.**



## Иң - иң...

* Иң җиңел агач - бальза. Ул судан 9 мәртәбә җиңелрәк. Әмма бу агачта агач матдәсе 7 генә процент. Иң авыр агач - гваяк. Ул судан 1,37 тапкыр авыррак һәм аның 87 процентын агач матдәсе тәшкил итә.

* Иң биектә яшәүчеләр - үрмәкүчләр. Алар тауларда 7500 метр биеклектә яши алалар. Бу үрмәкүчләр җил нәрсә китерсә, шуның белән тукланалар. Кошлар 4500 метр биеклектә, ә кайбер күбәләкләр тауларда 6000 метр биеклектә яшиләр.

* Иң тиз очучы кошлар дип карлыгачлар санала иде. Алардан да тиз очучы лачын бар. Ул карлыгачларны очканда куып җитеп тота. Иң ерак һәм иң югарыда очучылар - бөркетләр һәм грифлар.

* Дөньядагы иң зур бака (аларның 250 төре бар!) - голиаф дигән бака. Ул Африка джунглиларында яши. Буе 90 сантиметр, авырлыгы 3 килограмм. Америкада 600 граммлы үгез - бака бар. Аның итен ашыйлар, кыйммәтле рестораннарда ул деликатес итеп бирелә.


* Иң озак яшәүче агач - секвойя. Ул 5 мең елдан артык яши. Күптән түгел Мисыр пирамидалары белән яшьтәш нарат агачлары тапканнар. Иң карты - 4600 ел яшәгән чал нарат.

# *КОТЛЫЙБЫЗ*

Иске Әмзә авылында гомер итүче сөекле әниебез **Наилә**, әтиебез **Мәҗит Кәлимуллиннарның** матур, тату гаилә коруларына 8 ноябрьдә 50 ел тула.

Әти - әни яшәгез сез
Авырлыкларны белмичә.
Тормыш юлларыгыз үтсен
Кайгы - хәсрәт күрмичә.

**Улыгыз Әдип, киленегез Гөлсирә, оныкларыгыз Лилия, Ландыш.**



# Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**1993 нче елгы «каблук Москвич»ы, кыйммәт түгел.** Адрес: Карбышев ур., 6 - 1.

***

**1988 нче елгы ВАЗ - 21061, яңа двигатель 03, 16 млн. сум.** Тел.: 5 - 25 - 90.

***

**Мутон тун.** Тел.: 5 - 25 - 50.

***

**Ашыгыч рәвештә Кузнецов урамындагы 13 нче йорт, «Урал» мотоциклы, 7 мең км. юл үткән.** Адрес: Гыйматдинов ур., 130 - 8.

***

**1982 нче елгы «Москвич - 2140», 7 млн. сум, сатулашырга мөмкин.** Адрес: Дружба ур., 69 - 46.

***

**Шифер, силикат һәм тышлау кирпечләре.** Тел.: 5 - 21 - 22, 15 сәг.тән 17 сәг.кә кадәр.

***

**1993 нче елгы ак төстәге ВАЗ - 2106.** Адрес: Кошки авылы, Мир ур., 40.

***

**1996 нчы елның мартында чыккан ВАЗ - 21083.** Адрес: Гагарин ур., 6 - 14.

***

**«Москвич - 412», алып китү өчен металл гараж.** Адрес: Козлов ур., 16 - 17, тел.: 5 - 23 - 17.

***

**4 яшьлек бия, 1,5 яшьлек тай сатыла яки бозауга алыштырыла.** Тел.: 3 - 62 - 46 (эш), Семенова.

***

**Кулланышта булган стенка һәм йомшак мебель, кыйммәт түгел.** Тел.: 5 - 25 - 85.

***

**«Алмалык»та дача, чит илдә эшләнгән тегү машинасы.** Тел.: 5 - 27 - 16.

***

**1997 нче елның маенда чыккан «УАЗ - 31512 - 10».** Тел.: 65 - 5 - 39.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**«Наркодел» оешмасы гафу үтенә, 3 нче ноябрьгә билгеләнгән консультация 10 нчы һәм 24 нче ноябрьләргә күчерелә.**

**«Наркодел» алкогольгә бәйлелектән азат итү өчен зыянсыз һәм нәтиҗәле чәй. Аноним кабул итәргә мөмкин. Район мәдәният йортына** 11 сәг.тән 13 сәг.кә кадәр мөрәҗәгать итәргә, керү ирекле. Лицензия 000102, 28. 09. 95 елда Мәскәүнең ФД тарафыннан бирелгән.

***

**Ике һәм бер бүлмәле фатирлар өч бүлмәлегә алыштырыла (шикәр заводы һәм тимер юл бистәләреннән тәкъдим итмәскә).** Тел.: 5 - 16 - 44.

### ТАБЫЛДЫКЛАР ӨСТӘЛЕ

**1 нче ноябрьдә 17 сәг.тә шәһәр мунчасы янында ачкычлар табылды.** Советская ур., 70 - 14 адресына мөрәҗәгать итәргә.

***

**Автовокзал мәйданында ачкычлар табылды.** Район элемтә узелында хат ташучыларга мөрәҗәгать итәргә.

## Искә алыгыз

Быелның 8 ноябрендә кадерле ирем һәм әтиебез Рәшит Гали улы Кәримовның безнең арабыздан китүенә бер ел тула. Рәшитне белгән һәр кешене аны искә алуын сорыйбыз.

**Хатыны, балалары, туганнары.**


### *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 7, 21ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә. 9423